МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.05.2019 г.Казань № 331

Боерык Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2019 елның 29 маеда 5592 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Дәүләт хезмәтләрен күрсәтү эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2018 елның 16 октябрендәге 950 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче

урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 07.05.2019 № 331 боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2016 елның 18 февралендәге 78 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре юлламасы буенча эшкә урнашу өчен, эшсез гражданнарга бер урыннан икенче урынга күченүдә һәм эшсез гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына башка җирлеккә күченеп урнашуда булышлык итү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1 бүлектә:

1.8 пунктның уналтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Халыкны эшкә урнаштыруга булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре алучының шәхси эш бланклары формаларын раслау турында» 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгы боерыгы (алга таба – 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерык) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2019, 19 март, басылып чыгу номеры: 0001201903190024)»;

1.9 пунктның җиденче абзацында «26.02.2015 ел, № 125н боерык белән» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерык белән» сүзләренә алмаштырырга;

2 бүлектә:

2.3 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының икенче абзацында «26.02.2015 ел, № 125н боерыкка 8 нче кушымта» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерыкка 7 нче кушымта» сүзләренә алмаштырырга;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Халыкка эшкә урнашуда булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 13 нче кушымтага туры китерелгән формалы гариза (алга таба – гариза) яки халыкның мәшгульлек үзәге белгече тарафыннан бирелгән халыкны эшкә урнаштыруда булышлык күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәте күрсәтү турында 2019 елның 19 февралендәге 90н номерлы боерыкка 14 нче кушымтага туры китерелгән формалы тәкъдим (алга таба – халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдиме)

һәм дәүләт хезмәте алучының халыкның мәшгульлек үзәге белгече тәкъдименә ризалыгы.»;

3 бүлектә:

3.4.2 пунктның 3.4.2.1 пунктчасында:

беренче абзацта «26.02.2015 ел, № 125н боерык белән (37 нче кушымта)» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерык белән (13 нче кушымта)» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшсез гражданинның гаризасы халыкның мәшгульлек үзәгенә язмача формада почта адресы буенча, электрон документ формасында электрон почта адресы буенча, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша килгән очракта яки гариза КФҮ, читтән торып эшләү урыны аша тапшырылганда, мәшгульлек үзәге белгече гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән көннән килүче эш көненнән соңга калмыйча гражданин белән шәхси кабул итү датасын, вакытын килештерә. Эшсез гражданин белән халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итү датасын һәм вакытын килештерү, «Интернет» челтәрен дә кертеп, телефон яки электрон элемтә чараларыннан, почта элемтәсеннән файдаланып, гаризаны теркәгән көннән соң килгән эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

3.4.2.2 пунктчаның алтынчы абзацында «26.02.2015 ел, № 125н боерык белән (38 нче кушымта)» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерык белән (14 нче кушымта)» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.7 пунктның икенче абзацында «26.02.2015 ел, № 125н боерыкка 8 нче кушымта» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерыкка 7 нче кушымта» сүзләренә алмаштырырга;

3.4.12 пунктның икенче абзацында «26.02.2015 ел, № 125н боерыкка 8 нче кушымтага» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерыкка 7 нче кушымтага» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.2 пунктның 3.5.2.1 пунктчасында:

беренче абзацта «26.02.2015 ел, № 125н боерык белән (37 нче кушымта)» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерык белән (13 нче кушымта)» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Эшсез гражданинның гаризасы халыкның мәшгульлек үзәгенә язмача формада почта адресы буенча, электрон документ формасында электрон почта адресы буенча, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси кабинет аша килгән очракта яки гариза КФҮ, читтән торып эшләү урыны аша тапшырылганда, мәшгульлек үзәге белгече гариза халыкның мәшгульлек үзәгенә килгән көннән килүче эш көненнән соңга калмыйча гражданин белән шәхси кабул итү датасын, вакытын килештерә. Эшсез гражданин белән халыкның мәшгульлек үзәгенә мөрәҗәгать итү датасын һәм вакытын килештерү, «Интернет» челтәрен дә кертеп, телефон яки электрон

элемтә чараларыннан, почта элемтәсеннән файдаланып, гаризаны теркәгән көннән соң килгән эш көненнән соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.»;

3.5.2.2 пунктчаның алтынчы абзацында «26.02.2015 ел, № 125н боерык белән (38 нче кушымта)» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерык белән (14 нче кушымта)» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.8 пунктның икенче абзацында «26.02.2015 ел, № 125н боерыкка 8 нче кушымта» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерыкка 7 нче кушымта» сүзләренә алмаштырырга;

3.5.13 пунктның икенче абзацында «26.02.2015 ел, № 125н боерыкка 8 нче кушымтага» сүзләрен «19.02.2019 ел, № 90н боерыкка 7 нче кушымтага» сүзләренә алмаштырырга;

5 бүлектә:

5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Дәүләт хезмәтен алучылар судка кадәр тәртиптә халыкның мәшгульлек үзәгенең дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи заты (белгече) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесенә дәгъва белдерү хокукына ия.

Халыкның мәшгульлек үзәге җитәкчесе карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр Министрлыкка министр исеменә тапшырыла.

Министр карарларына, гамәлләренә (гамәл кылмавына) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына шикаять белдерелергә мөмкин.

КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮ җитәкчесенә белдерелә, КФҮ җитәкчесе карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата – КФҮ гамәлгә куючыга.»;

Регламентка 1 нче кушымтада:

кушымтаның аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү һәм аның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру өчен җаваплы органнар һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр»;

«Татарстан Республикасы халыкның мәшгульлек хезмәте дәүләт учреждениеләре» дигән 1 нче таблицада:

егерме дүртенче юлны киләсе редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Кукмара районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84364) 2-67-54 | 422110, Кукмара ш., Ворошилов ур.,44 Czn.Kukmor@tatar.ru»; |

егерме бишенче юлны киләсе редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| «Лаеш районы халыкның мәшгульлек үзәге» ДКУ | (84378) 2-48-12 | 422610, Лаеш ш., Беренче май ур., 35, Laish.Czn@tatar.ru»; |

Регламентка 2 нче кушымтада:

«Шәхсән, почта аша, ш.и. КФҮ аша, электрон формада гариза һәм 2.5 пунктның 1 пунктчасы нигезендә документлар тапшыру» сүзләрен: «Гаризаны шәхсән, язмача формада почта адресы буенча, электрон документ формасында электрон почта адресы буенча, ш.и. КФҮ аша, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы»ндагы шәхси кабинет аша һәм 2.5

пунктның 1 пунктчасы нигезендә документларны тапшыру» сүзләренә алмаштырырга;

Регламентка 3 нче кушымтада:

«Шәхсән, почта аша, ш.и. КФҮ аша, электрон формада гариза һәм 2.5 пунктның 1 пунктчасы нигезендә документлар тапшыру» сүзләрен: «Гаризаны шәхсән, язмача формада почта адресы буенча, электрон документ формасында электрон почта адресы буенча, ш.и. КФҮ аша, «Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр порталы»ндагы шәхси кабинет аша һәм 2.5 пунктның 1 пунктчасы нигезендә документларны тапшыру» сүзләренә алмаштырырга.